ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.М.Джалиля, д.23/33, г. Мамадыш,
Республика Татарстан, 422190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
М.Җәлил ур, 23/33 й., Мамадыш ш.,
Татарстан Республикасы, 422190

Тел.: (85563) 3-15-00, 3-31-00, факс 3-22-21, e-mail: mamadysh.ikrayona@tatar.ru, www.mamadysh.tatarstan.ru

**Постановление** **Карар**

№ 1593 от «22 » 12 2017 г.

Кулланучылар кооперациясе тарафыннан
Мамадыш шәһәреннән 11 км дан артык
ераклыкта урнашкан аз халыклы торак
пунктларга көнкүреш кирәк- яраклары китерү
белән бәйле чыгымнарны каплау өчен
Мамадыш муниципаль район бюджетыннан
субсидия бирү тәртибен раслау турында

Мамадыш муниципаль районы составына керүче җирлекләрдә яшәүчеләрне «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы нигезендә сәүдә хезмәтләре белән тәэмин итү өчен шартлар тудыру буенча Мамадыш муниципаль районы вәкаләтләрен гамәлгә ашыру максатларында, Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78 статьясы, Татарстан Республикасы «Мамадыш муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә бюджет процессы турында нигезләмәнең 9 статьясындагы 3 пункты, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 елның 20 ноябрендәге 887 номерлы карары,Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 елның 31 октябрендәге№ 2854-р боерыгы нигезендә, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Кулланучылар кооперациясе тарафыннан Мамадыш шәһәреннән 11 км дан артык ераклыкта урнашкан аз халыклы торак пунктларга көнкүреш кирәк-яраклары китерү белән бәйле чыгымнарны каплау өчен Мамадыш муниципаль район бюджетыннан субсидия бирү тәртибен 1 нче кушымта нигезендә расларга.

2. Кулланучылар кооперациясе оешмаларының беренче кирәкле товарларны Мамадыш шәһәреннән 11 километр ераклыкта урнашкан ерак һәм аз кеше яшәгән авыл пунктларына китерү чыгымнарының бер өлешен каплауга Мамадыш муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү мәсьәләләрен карау буенча комиссия составын расларга (килешү буенча) (әлеге карарга 2 нче кушымта).

3. Әлеге карар белән расланган тәртип буенча башкарыла торган чыгымнарны финанслау Мамадыш муниципаль районы бюджетында тиешле финанс елына каралган акчалар чикләрендә башкарыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче вазифаларын
башкаручы И.М.Дәрҗеманов

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының 22.12.2017 ел, № 1593 карарына 1 нче кушымта

Кулланучылар кооперациясе тарафыннан Мамадыш шәһәреннән 11 км дан артык ераклыкта урнашкан аз халыклы торак пунктларга көнкүреш кирәк- яраклары китерү белән бәйле чыгымнарны каплау өчен Мамадыш муниципаль район бюджетыннан субсидия бирү тәртибе

1. Гомуми нигекзләмәләр

1.1. Әлеге Нигезләмә кулланучылар кооперациясе оешмаларының беренче кирәкле товарларны Мамадыш шәһәреннән 11 километр ераклыкта урнашкан ерак һәм аз кеше яшәгән авыл пунктларына китерү белән бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау өчен ТР Мамадыш муниципаль районы бюджеты акчалары хисабына бирү тәртибен билгели.

1.2. Субсидияләр Мамадыш муниципаль районы бюджетында Мамадыш шәһәреннән 11 километр ераклыкта урнашкан ерак һәм аз кеше яшәгән авыл пунктларына беренче кирәкле товарлар китерү белән бәйле куллану кооперациясе оешмалары чыгымнарының бер өлешен каплауга каралган акчалар чикләрендә бирелә

2. Субсидия бирүнең максатлары, шартлары һәм тәртибе

2.1. Субсидия бирүнең максаты-«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы нигезендә ерак торак пунктларда яшәүче Мамадыш муниципаль районы составына керүче торак пунктларда яшәүчеләрне беренче кирәкле товарлар белән тәэмин итү.

2.2. Субсидия алучылар - Мамадыш муниципаль районы территориясендә теркәлгән һәм эшчәнлек алып баручы кулланучылар кооперациясе оешмалары (алга таба- сатып алучылар).

2.3. Субсидияләр бирү шартлары булып түбәндәгеләр тора:

- Мамадыш муниципаль районы территориясендә сатып алучының сәүдә эшчәнлеген теркәү һәм гамәлгә ашыру;

- азык-төлек ташу өчен транспорт чаралары булу;

-Мамадыш муниципаль районының ерак торак пунктларына атнага 1-4 тапкыр товарлар китерүне тәэмин итү;

үзгәртеп кору, бетерү яки банкротлык стадиясендә булмау.

2.4. Беренче кирәкле товарларны китерү буенча ягулык-майлау материалларына транспорт чыгымнары кире кайтарылырга тиеш.

2.5. Субсидия алу өчен алучы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының территориаль үсеш бүлегенә түбәндәге документларны тапшыра:
- субсидия бирүгә гариза;
юридик затның дәүләт теркәве турында таныклыкның яки язманы юридик затларның бердәм дәүләт реестрына кертү турында таныклыкның алучы тарафыннан расланган күчермәсе;
- транспорт чаралары булуын раслаучы документлар (техник чара паспорты күчермәләре һ. б.)
-беренче кирәкле продуктларны һәм товарларны ташуга кирәкле ягулык-майлау материаллары сатып алу чыгымнарын исәпләү (беренчел документация кушымтасы белән).

2.6. Субсидияләрне күчерү өчен нигез булып, әлеге Тәртипкә 1 нче кушымта нигезендә, алучы белән Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты арасында төзелгән Килешү тора.

2.8.Субсидия бирү турындагы килешү буенча йөкләмәләр үтәлмәгән очракта, шулай ук тапшырылган документларда дөрес булмаган яки тулы булмаган мәгълүмат булган очракта, Субсидия Мамадыш муниципаль районы бюджетына кайтарылырга тиеш. Субсидия алучы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетыннан субсидияне кире кайтару турындагы таләпне алганнан соң 15 (унбиш) банк көне эчендә акчаларын кире кайтарырга тиеш. Субсидияне бюджетка кайтару турындагы таләпне үтәмәгән очракта, субсидия алучы Россия Федерациясенең гамәлдәге законнары нигезендә җаваплы.
Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты субсидия алучыдан субсидия суммаларын Россия Федерациясе законнары нигезендә мәҗбүри рәвештә түләтү буенча чаралар күрә.

2.9. Субсидияләр биргәндә, субсидияләр бирү турындагы килешүгә кертелә торган аларны бирүнең мәҗбүри шарты булып, аларны алучыларның субсидияләр биргән бюджет акчаларын баш идарәче һәм Мамадыш муниципаль районының муниципаль финанс контроле органнары тарафыннан субсидияләр алучыларның аларны бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәүләрен тикшерүгә ризалыгы тора.

2.10. Субсидия алучы законнарда билгеләнгән тәртиптә тапшырылган документларның вакытында һәм ышанычлы булуы өчен җаваплы.

2.11. Хисап финанс елында кулланылмаган субсидия калдыклары суммалары, субсидия бирү турында килешүдә каралган очракларда, субсидия алучы тарафыннан хисап финанс елында тиешле бюджетка кайтарылырга тиеш.

Татарстан Республикасы Мамадыш
муниципаль районы Башкарма
комитетының 22.12.2017 ел, № 1593
карарына 2 нче кушымта

Кулланучылар кооперациясе оешмаларының беренче кирәкле товарларны Мамадыш шәһәреннән 11 километр ераклыкта урнашкан ерак һәм аз кеше яшәгән авыл пунктларына китерү чыгымнарының бер өлешен каплауга Мамадыш муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү мәсьәләләрен карау буенча комиссия составы

| №п/п | вазифа | Ф.И.О. |
|---|---|---|
| 1. | Рәис- Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы | И.М.Дәрҗеманов |
| 2. | Рәис урынбасары - Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының территориаль үсеш бүлеге башлыгы | А.Г.Әскәров |
| | Комиссия әгъзалары: | |
| 1. | Мамадыш муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы җитәкчесе | А.М. Сергеев |
| 2. | Мамадыш муниципаль районы Иҗтимагый советы рәисе | Х.Г. Кәримов |

Кулланучылар кооперациясе тарафыннан Мамадыш шәһәреннән 11 км дан артык ераклыкта урнашкан аз халыклы торак пунктларга көнкүреш кирәк- яраклары китерү белән бәйле чыгымнарны каплау өчен Мамадыш муниципаль район бюджетыннан субсидия бирү тәртибенә 1нче кушымта

**Мамадыш муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү турында килешү**

"__" __________ 20__ ел

Мамадыш муниципаль районы башкарма комитеты, Устав нигезендә эш итүче җитәкче буларак, бер яктан "Башкарма комитет" дип атала, и ____________________________________, алга таба "субсидияләр алучы" дип атала, __________________, нигезендә эш итүче_______________, икенче яктан, бергәләп аталган яклар, Мамадыш муниципаль районы бюджетыннан кулланучылар кооперациясе оешмаларының Чистай шәһәреннән 11 километр ераклыкта урнашкан ерак һәм аз халыклы авыл пунктларына беренче кирәкле товарлар китерү белән бәйле чыгымнарның бер өлешен каплауга субсидияләр бирү максатыннан, түбәндәгеләр турында әлеге килешү төзеделәр:

1. I. Килешү Предметы

1.1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Мамадыш шәһәре муниципаль берәмлегеннән 11 километр ераклыкта урнашкан Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының ерак һәм аз халыклы авыл пунктларына беренче чиратта кирәкле товарлар китерүгә бәйле чыгымнарның бер өлешен каплауга Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү әлеге Килешү предметы булып тора (алга таба- субсидия).

1.2.II. Субсидияләр бирүнефинанс белән тәэмин итү

2.1. Субсидияләр Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Башкарма комитетына әлеге Килешү I бүлегендә күрсәтелгән максатларга Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы бюджеты акчаларын алучыга җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары нигезендә түбәндәге күләмдә бирелә:
БК коды буенча________ ________ (______________________________) сум.

III. Субсидияләр бирүнең
шартлары һәм тәртибе

3.1. Субсидияләр субсидияләр бирү Кагыйдәләре нигезендә бирелә:
3.1.1. әлеге килешүнең I бүлегендә күрсәтелгән максатларга:

3.1.2. субсидияләр алучыга субсидияләр бирү кагыйдәләре һәм әлеге килешү нигезендә субсидия бирелә торган чыгымнарның бер өлешен субсидия алучы җитештергән фактны раслаучы Башкарма комитетка тапшырганда.
3.2. Субсидияләрне күчерү Россия Федерациясе Бюджет законнары нигезендә, субсидия алучыга
_______________________________________________ ачылган Алучы счѐтына гамәлгә ашырыла.
3.2.1 Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының “Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Мамадыш шәһәре” муниципаль берәмлегенең 11 чакрым ерак һәм аз халыклы авыл пунктларына беренче чиратта кирәкле товарлар китерүгә бәйле чыгымнарны каплауга субсидия күләмен исәпләү акты Башкарма комитет тарафыннан акча күчерүгә нигез булып тора.
3.3. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты һәм Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Контроль-хисап палатасы субсидияләр бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәүне мәҗбүри тикшерүне үткәрәләр.
4.4. Әлеге килешү нигезендә, алучы Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Башкарма комитеты һәм Контроль-хисап палатасы субсидия алучыларның субсидия бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәүне тикшерүне гамәлгә ашыруга ризалыгын раслый.

IV. Якларның Үзара хезмәттәшлеге

4.1. Башкарма комитет түбәндәгеләрне йөкләп ала:
4.1.1. әлеге Килешүнең III бүлеге нигезендә субсидияләр бирүне тәэмин итәргә;
4.1.2. Алучы тарафыннан әлеге килешүнең 3.1 пунктларында күрсәтелгән документларны алучыдан алган көннән алып 15 эш көне эчендә тикшерүне гамәлгә ашырырга;
4.1.3. әлеге Килешүнең 3.2 пункты нигезендә күрсәтелгән Алучы счетына субсидияләр күчерүне тәэмин итәргә;
4.1.4. субсидия бирү кагыйдәләре һәм әлеге Килешү белән билгеләнгән субсидияләр бирү тәртибен, максатларының һәм шартларының планлы һәм (яки) планнан тыш тикшерүләрне үткәрү юлы белән үтәлешен контрольдә тотуны гамәлгә ашырырга:
4.1.4.1. Башкарма комитет запросы буенча Алучы тарафыннан тәкъдим ителгән документлар;
4.1.5. Башкарма комитет тарафыннан билгеләү яисә дәүләт (муниципаль) финанс контроле органыннан субсидия бирү кагыйдәләре һәм әлеге килешү нигезендә каралган субсидия бирү тәртибен, максатларын һәм шартларын бозу турында мәгълүмат алу очрагында, шул исәптән әлеге килешү нигезендә Алучыга тапшырылган документларда күрсәтелмәгән белешмәләр күрсәтелгән очракта, Алучыдан Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы бюджетына күрсәтелгән таләптә билгеләнгән срокта субсидияләрне кире кайтаруны таләп итү җибәрергә;
4.1.6. Алучы тарафыннан җибәрелгән тәкъдимнәрне, документларны һәм

башка мәгълүматны, шул исәптән әлеге Килешүнең 4.4.1 пункты нигезендә, аларны алган көннән алып 5 эш көне эчендә карарга һәм кабул ителгән карар турында (кирәк булганда)Алучыга хәбәр итәргә;
4.1.7. Россия Федерациясе бюджет законнары һәм субсидияләр бирү Кагыйдәләре нигезендә башка йөкләмәләрне үтәргә.
4.2. Башкарма комитет хокуклы:
4.2.1. Башкарма комитет тарафыннан билгеләнгән яисә дәүләт (муниципаль) финанс контроле органыннан мәгълүмат алган очракта, субсидияләр бирүне Алучы тарафыннан башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен, максатларын һәм шартларын бозган очракта, шул исәптән әлеге килешү нигезендә Алучы тарафыннан тапшырылган документларда күрсәтелмәгән белешмәләрне күрсәтелгән әлеге хокук бозуларны, җитешсезлекләрне бетергәнчегә кадәр, мәҗбүри рәвештә субсидия бирү турында карар кабул ителгән көннән________ туктатып торырга;
4.2.2. әлеге килешүнең 4.1.6 пункты нигезендә Алучыга субсидия бирү тәртибен, максатларын һәм шартларын үтәүне тикшереп торуны гамәлгә ашыру өчен кирәкле документларны һәм мәгълүматны соратып алырга;
4.2.3. Россия Федерациясе Бюджет законнары һәм башка бюджетара трансфертлар бирү Кагыйдәләре нигезендә башка хокукларны гамәлгә ашырырга.
4.3. Алучы түбәндәгеләрне йөкләп ала:
4.3.1. соралган документларны Башкарма комитетка тапшырырга;
4.3.2. әлеге килешүнең 4.2.2 пункты нигезендә субсидияләр бирү тәртибен, максатларын һәм шартларын үтәүне контрольдә тотуны гамәлгә ашыру өчен кирәкле документларны һәм мәгълүматны әлеге гарызнамә (запрос) алган көннән алып 3 эш көне эчендә җибәрергә;
4.3.4. Башкарма комитеттан таләп алынган очракта әлеге Килешүнең 4.1.5 пункты нигезендә Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы бюджетына күрсәтелгән таләптә билгеләнгән күләмдә һәм срокта субсидияләрне кире кайтарырга;
4.3.5. әлеге Килешү нигезендә Башкарма комитетка тапшырыла торган мәгълүматларның тулылыгын һәм дөреслеген тәэмин итү;
4.3.6. әлеге Килешүдә каралган хокукларны өченче затларга юл куймаска, шулай ук әлеге Килешүдә каралган йөкләмәләрне, өченче затларны җәлеп итмичә, мөстәкыйль үтәргә;
4.3.7. әлеге Килешү кысаларында бирелгән акчаларны максатчан файдалану турында хисап бирергә;
4.3.8. Россия Федерациясе Бюджет законнары нигезендә башка йөкләмәләрне үтәү.
4.4. Алучы хокуклы:
4.4.1. әлеге Килешүгә үзгәрешләр кертү турында Башкарма комитетка, шул исәптән, әлеге үзгәрешнең финанс-икътисадый нигезендәге мәгълүмат кушып, субсидияләр күләмен үзгәртү кирәк булган очракта да тәкъдимнәр җибәрергә;
4.4.2. Россия Федерациясе Бюджет законнары нигезендә башка хокукларны гамәлгә ашырырга.

## V. Субсидияләрне кире кайтару тәртибе

5.1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Башкарма комитеты һәм Контроль-хисап палатасы тарафыннан субсидияне максатсыз файдалану факты ачыкланган очракта, Башкарма комитет субсидия Алучыга Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы бюджетына алынган субсидияне кире кайтару турында таләп җибәрә.
5.2. Субсидияләрне кире кайтару субсидия Алучы тарафыннан субсидия кире кайтару турындагы таләп алынганнан соң 30 көн эчендә Башкарма комитетның исәп-хисап счетына акча күчерү юлы белән башкарыла.
5.3. Субсидия Алучы субсидияне кире кайтарудан баш тарткан очракта, акчалар Россия Федерациясенең гамәлдәге законнары нигезендә суд тәртибендә түләтелә.

## VI. Якларның җаваплылыгы

5.1. Әлеге Килешү буенча үз йөкләмәләрен үтәмәгән яисә тиешенчә үтәмәгән очракта, яклар Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплы.

## VII. Йомгаклау нигезләмәләре

7.1. Яклар арасында әлеге Килешүне гамәлгә ашыру белән бәйле килеп туган бәхәсләр алар тарафыннан, мөмкин булганча, тиешле беркетмәләрне яки башка документларны рәсмиләштерү белән сөйләшүләр уздыру юлы белән хәл ителә. Килешмәгән очракта, яклар арасындагы бәхәсләр суд тәртибендә хәл ителә.
7.2. Әлеге Килешү һәр як исеменнән эш итәргә хокуклы, әмма әлеге Килешүнең 2.1 пунктында күрсәтелгән бюджет йөкләмәләре лимитларын элек җиткермәү хокукына ия затлар тарафыннан кул куелган көннән үз көченә керә һәм яклар тарафыннан әлеге Килешү буенча үз йөкләмәләрен тулысынча үтәүгә кадәр гамәлдә була.
7.3. Әлеге Килешүне үзгәртү, шул исәптән әлеге Килешүнең 4.2.1 пункты нигезләмәләре нигезендә дә, яклар Килешүе буенча гамәлгә ашырыла һәм әлеге Килешүнең аерылгысыз өлеше булып торган әлеге Килешүгә өстәмә Килешү рәвешендә рәсмиләштерелә.
7.4. Әлеге Килешүне өзү түбәндәге очракта мөмкин:
7.4.1. (алучы шәхси эшмәкәр, товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр җитештерүче физик зат булса), аны үзгәртеп кору яисә туктату күздә тотылмый;
7.4.2. субсидия бирү кагыйдәләре һәм әлеге Килешү белән билгеләнгән субсидияләр бирү тәртибен, максатларын һәм шартларын бозу;
1.5. Әлеге Килешү яклар тарафыннан ике нөсхәдә кәгазь документ рәвешендә, һәр як өчен берәр нөсхәдә төзелгән.

## VIII. Якларның түләү реквизитлары

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы башкарма комитеты
Юридик адрес: 422190, ТР, Мамадыш ш., Муса Җәлил ур, 23/33
Фактик адрес: шул ук
ИНН: 1626008921, КПП: 162601001
Банк реквизитлары:

Р/счет 40204810400000000046
Милли Банк бүлекчәсе Татарстан Республикасы
БИК 049205001
Татарстан Республикасы буенча Федераль салым хезмәтенең 26 нчы бүлеге (ТР Мамадыш муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы) л/с 02113000770)
________________/И.М.Дәрҗеманов/
м.у.